КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 10 июнь г.Казань № 547

Казан шәһәре, Чехов урамы, 53 нче йорт адресы буенча урнашкан бина фасадына мемориаль такта кую турында

1989 - 1991 елларда ТАССР Министрлар Советы Рәисе, 1991 - 1995 елларда Татарстан ССР, Татарстан Республикасы Премьер-министры Сабиров Мөхәммәт Галләм улы хәтерен мәңгеләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Казан шәһәре, Чехов урамы, 53 йорт адресы буенча бина фасадына М.Г.Сабировка татар һәм рус телләрендә түбәндәге текст белән мемориаль такта кую турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

«Бу йортта 1999 – 2015 елларда
күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе,
ТАССРның Министрлар Советы Рәисе,
Татарстан Республикасының
беренче Премьер-министры
Мөхәммәт Галләм улы Сабиров
яшәде

---

В этом доме в 1999 – 2015 гг. жил
видный государственный и общественный деятель,
Председатель Совета Министров ТАССР,
первый Премьер-министр Республики Татарстан
Мухаммат Галлямович Сабиров».

2. Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә мемориаль тактаның баланста тотучысын билгеләүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин